| | |
|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**<br>**ГЛАВА**<br>**Терсинского сельского поселения**<br>**Агрызского муниципального района** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**<br>**Әгерже муниципаль районы**<br>**Тирсә авыл җирлеге**<br>**БАШЛЫГЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25.11.2019 Тирсә авылы № 3

Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районы Тирсә авыл җирлеге Мордыбый авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары, Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районы Тирсә авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районы Тирсә авыл җирлеге башлыгы к а р а р б и р д е:

1. Мордыбый авылындагы ФАП бинасында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2019 елның 6 декабре 10 сәгать 00 минутта билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге сорауны расларга: «Тирсә авыл җирлегенең Мордыбый авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I группа инвалидлар, ялгыз яшәүче өлкән кешеләрдән (80 яшькә җиткән), торып укучы студентлардан, иректән мәхрүм ителгән физик затлардан тыш, 2020 елда узара салым акчасын 1000 сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итәргә юнәлтергә Сез ризамы:

1. Кышкы чорда урамнарны кардан чистарту
2. Мордыбый авылында халыкны су белән тәэмин итү өчен скважина бораулау

«ӘЙЕ» «ЮК".

3. Тирсә авыл җирлеге Башкарма Комитетына халык җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә.

4. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә җирлекнең мәгълүмат стендларында урнаштыру, http://pravo.tatarstan.ru Татарстан

Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм http://agryz.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Әгерҗе муниципаль районы сайтында бастырып чыгару юлы белән халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Р.Р. ЗАКИРОВ